# КАРАР

**05 апрель 2024 ел № 2**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Югары Әзәк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Югары Әзәк авылында гражданнарның җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм «Иске Кырлайавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль. районының 2024 елның 05 апрелендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге Югары Әзәк авылында «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлегенең Югары Әзәк авылында гражданнарның җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелгән:

«Сез 2024 елда Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Югары Әзәк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 600 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан 300 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау Югары Әзәк авылы, Гомәр Бәширов урамы)?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 92 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 47 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар

тавышы түбәндәгечә бүленде: "Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 43 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 4 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегендә Югары Әзәк авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2.«Сез 2024 елда Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Югары Әзәк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 600 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан 300 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы?

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау Югары Әзәк авылы, Гомәр Бәширов урамы) , карар кабул ителгән дип танырга».

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы Югары Әзәк авылы, Гомәр Бәширов урамы, 21 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Лутфуллин Ф.Ф.